ГЛАВА ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“13 ” август 2018 ел | № 3

Олыяз авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 22 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә мөһер һәм штампларны исәпкә алу, әзерләү, куллану, саклау һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 6 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 27 декабрендәге «Дәүләт гербы күчереп ясалган мөһерләрне һәм бланкларны әзерләүне, алардан файдалануны, саклауны һәм юк итүне тәртипкә салу турында» 1268 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Олыяз авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 22 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә мөһер һәм штампларны исәпкә алу, әзерләү, куллану, саклау һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.3.Россия Федерациясе Дәүләт гербы күчереп ясалган продкуцияне җитештерү бары тик әлеге төр продукцияне тиешле дәрәҗәдә әзерләү өчен техник һәм технологик мөмкинлекләр булу турында сертификатлары булган полиграфик һәм штемпель-гравер предприятиеләре тарафыннан гына гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы /И.Я.Хаев/